ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 Казан ш. № 5-7/тэ

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционер җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында алучы җылылык челтәрләре оешмаларына бирә торган җылылык энергиясенә 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 2017 елның 15 декабрендәге 5-82/тэ номерлы карары кушымтасының 1.2 пунктына үзгәреш кертү турында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында"2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары нигезендә, шулай ук «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык энергиясен тапшыру хезмәтен күрсәтү буенча җайга салына торган эшчәнлеген туктатуына бәйле рәвештә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционер җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында алучы җылылык челтәрләре оешмаларына бирә торган җылылык энергиясенә 2018 – 2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 2017 елның 15 декабрендәге 5-82/тэ номерлы карары кушымтасының 1.2 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«КАМАЗ-Энерго» ҖЧҖ» сүзләрен «Көнбатышка таба китүче җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев